**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуган авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы №110 17 сентябрь 2018 ел.

Татар Шуган авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законынын 18 статьясы, Татар Шуган авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татар Шуган авылы жирлеге башкарма комитетынын 03 сентябрь 2018 елда чыккан 13 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Татар Шуган авыл җирлеге Советының 03 сентябрь 2018 елда чыккан 109 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Татар Шуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татар Шуган авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 18 ноябрь 2018 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

"Сез, Татар Шуганы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) авыл жирлегенен авыл эчендәге юллары эшчәнлеген булдыру (Татар Шуган авылы Совет, Сэйдэш, Х.Такташ урамнары юлларын щебенка белән каплау);

2) авыл кешеләренең ялын оештыруга мөмкинлекләр тудыру (бәйрәм чаралары үткәрү һәм оештыру-Сабантуй, Олкэннэр коне);

3) авыл биләмәсен төзекләндерүне оештыру ("Урман чишмэсе"н тозеклэндеру);

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасының хокук мәгълүмәтләре интернет челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Г.З.Мияссарова